# Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең
# 6 нчы сыйныфында укучы татар балалары өчен
# татар теленнән үткәрелә торган район олимпиадасы биремнәре
# (2015/2016 нчы уку елы)

**Үткәрү вакыты- 3 сәгать** **Максималь балл - 50**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. **Морфология** терминын дөрес аңлаткан вариантны билгеләгез. ***(2 балл)***
   а) тел белемендә сүзләрнең мәгънәсен өйрәнә торган тармак;
   ә) тел белемендә сүзләрнең төзелешен өйрәнә торган тармак;
   б) грамматиканың сүз формаларын өйрәнә торган бүлеге;
   в) тел белемендә сүзләрнең дөрес әйтелешен өйрәнә торган бүлек.

2. **Конкрет исемнәр** дигән мәгънә төркемчәсенә туры килгән сүзләр рәтен билгеләгез. ***(2 балл)***
   а) кояш, яфрак, өстәл, дәрес;
   ә) чәй, күмер, май, ярма;
   б) җиләклек, каенлык, утынлык, чыршылык;
   в) акыл, уй, фикер, яхшылык.

3. Татар телендә ничә кыек килеш бар? ***(2 балл)***
   а) 6;
   ә) 5;
   б) 3;
   в) 4.

4. ***Әтиемнең*** *пианинода уйнавын мин сәгатьләр буе тыңлый идем* (А. Сәйдәшев) җөмләсендәге билгеләнгән сүзнең кайсы җөмлә кисәге икәнен күрсәтегез. ***(2 балл)***
   а) аергыч;
   ә) ия;
   б) хәбәр;
   в) тәмамлык.

5. Фразеологизмнар каршына аңлатмасының номерын язып куегыз. ***(6 балл)***

| | | |
|---|---|---|
| а) кулдан килү | | 1) вәгъдә бирү |
| ә) баш булу | | 2) буйсынмау |
| б) баш бала | | 3) уйлану |
| в) сүз бирү | | 4) булдыру |
| г) баш вату | | 5) ия яки хуҗа булу |
| д) баш бирмәү | | 6) беренче бала |

6. Татар телендәге иң күп кушымчалы килешне билгеләгез. ***(2 балл)***
   а) иялек килеше;
   ә) чыгыш килеше;
   б) урын-вакыт килеше;
   в) юнәлеш килеше.

7. *Әтиебез бик тырыш, көчле характерлы кеше иде* (Г. Исәнбәт) җөмләсендәге ***әтиебез*** сүзенә дөрес ясалган морфологик анализны билгеләгез. ***(2 балл)***

а) уртаклык исем, күплек санда, 1 зат күплек сан тартым белән төрләнгән, баш килештә, җөмләдә ия, тамыр исем;

ә) уртаклык исем, берлек санда, 1 зат күплек сан тартым белән төрләнгән, баш килештә, җөмләдә ия, ясалма исем;

б) уртаклык исем, берлек санда, 1 зат күплек сан тартым белән төрләнгән, баш килештә, җөмләдә ия, тамыр исем;

в) уртаклык исем, берлек санда, 1 зат берлек сан тартым белән төрләнгән, баш килештә, җөмләдә ия, тамыр исем.

8. **Җайланмалары** сүзенең мәгънәле кисәкләргә дөрес бүленгән вариантын билгеләгез. ***(2 балл)***

а) җай-лан-ма-лар-ы;
ә) җай-ла-н-ма-лар-ы;
б) җай-лан-ма-лары;
в) җайла-н-ма-лар-ы.

9. Кушма сүзләр рәтен билгеләгез. ***(2 балл)***

а) яшькелт, киңрәк, күгелҗем;
ә) Агыйдел, башкала, көнчыгыш;
б) сыйныфташ, яхшылык, җыелыш;
в) мүк җиләге, иртә-кич, җиләк-җимеш.

10. Ябык иҗекләрдән генә торган сүзләр төркемен билгеләгез. ***(2 балл)***

а) урманнар, ташландык, кайтырдай;
ә) фикерләр, эчтәлек, исемнәр;
б) алмый, килмәде, бүгенге;
в) төзелгән, җөмләләр, килешендә.

11. Артыклык дәрәҗәсендәге сыйфат булган җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) Төссез һәм соры көннәр үтеп киттеләр (Г.Хәсәнов);
ә) Аста – чиста ак кар, ә алар – җете кызыллар (Г.Хәсәнов);
б) Нинди матурлар, әйтерсең биш нурлы зәңгәрсу йолдызлар (Г. Әхмәт);
в) Хәмит үзеннән буйга аз гына кечерәк малайга карады (Р. Гыйззәтуллин).

12. *Яр астында тал яфракларында* ***көмештәй*** *саф иртәнге чык тамчылары ялтырый* (Г. Гобәй) җөмләсендә билгеләнгән сүз кайсы җөмлә кисәге? ***(2 балл)***

а) аергыч;
ә) хәбәр;
б) хәл;
в) тәмамлык.

13. ***Кадәр*** сүзенең беренче авазына кайсы характеристика туры килә? ***(2 балл)***

а) шаулы, йомык, саңгырау, тел арты авазы;
ә) шаулы, йомык, яңгырау, тел арты авазы;
б) шаулы, өрелмәле, саңгырау, кече тел авазы;
в) шаулы, йомык, саңгырау, кече тел авазы.

14. Кайсы раслау дөрес түгел? ***(2 балл)***

а) Аваз күп очракта бер хәреф белән белдерелә.

ә) Татар телендә берничә аваз белдерә торган хәрефләр дә бар.
б) Татар әлифбасында аваз белдерми торган хәрефләр юк.
в) Татар әлифбасында тартык авазлар да, сузыклар да бар.

15. Исемләшкән саннар кайсы җөмлә кисәге булып килә? ***(2 балл)***
а) төрле җөмлә кисәкләре;
ә) ия һәм хәбәр;
б) аергыч һәм тәмамлык;
в) аергыч һәм хәл.

**II Теоретик бирем.**

Татар телендә барлыгы ... сүз төркеме бар. Аларны берничә төрлегә бүлеп йөртәләр. Төрләрнең атамасын язып, аларга кайсы сүз төркемнәре керүен санагыз. ***(6 балл)***

**III Иҗади бирем.**

***"Балык сусыз, кеше дуссыз тора алмый"*** ди татар халык мәкале. Шушы мәкальгә бәйле фикерләрегезне, үзегезнең яшәү тәҗрибәсенә дә таянып, 12-13 җөмләдән торган текст итеп языгыз. ***(10 балл)***